**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 24 апреленнән № 9-57

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 29 декабрендәге 30-239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 пункты, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, депутатларга хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, муниципаль норматив хокукый базаны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2022 елның 29 декабрендәге 30-239 номерлы карары (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 12 июлендәге 35-282 номерлы, 2024 елның 23 маендагы 46-345 номерлы, 2024 елның 11 июлендәге 47-355 номерлы, 2024 елның 23 октябрендәге 49-375 номерлы, 2025 елның 17 апрелендәге 53-416 номерлы, 2025 елның 9 декабрендәге 4-25 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба-Карар) белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләгеп даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2.1 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү айлык акчалата түләүнең бер күләмендә;»;

1.2. Карарның 2.3 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү айлык акчалата түләүнең бер күләмендә;»;

1.2. Карарның 2.4 пунктындагы «, айлык акчалата түләүне һәм айлык акчалата стимуллаштыруны үз эченә алган бер айлык акчалата түләүдән артмаган,» сүзләрен «айлык акчалата бүләкләүне,» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский